ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ АКХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

2023 ел, 21 сентябрь № 102

Югары Акхуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Югары Акхуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законына туры китереп, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советы карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советының 2015 елның 26 февралендәге 91 номерлы “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының « Югары Акхуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Югары Акхуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәне раслау хакында”гы карары белән расланган Югары Акхуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Югары Акхуҗа авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәгә 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә:

«16. Муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, тулы булмаган белешмәләр тапшыру йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру күрсәтелгән гражданны муниципаль хезмәткә кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Муниципаль хезмәткәрләргә үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, мондый белешмәләрне мәҗбүри тапшырган очракта, йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, эштән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.

Муниципаль хезмәткәрләрнең белә торып дөрес булмаган әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Югары Акхуҗа авыл җирлеге Башлыгы,
Югары Акхуҗа авыл җирлеге Советының рәисе З.Я.Юзеев